## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Филимоновка торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

20 ноябрь 2025

№ 10

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Филимоновка торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Филимоновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Филимоновка торак пунктында традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (койма урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу).

3. Әлеге карарны Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы

А.М. Гыйльмуллин